**Принято**
**Педагогическим советом**
**Протокол №1 от 31.08.2023г.**
**Введен в действие приказом**
**№54 от 31.08.2023 г.**

Потапова Ирина Юрьевна

Подписан: Потапова Ирина Юрьевна
DN: C=RU, S=Республика Татарстан (Татарстан), L=Казань, T=Заведующая, O=" МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ""ДЕТСКИЙ САД №252 КОМБИНИРОВАННОГО ВИДА"" КИРОВСКОГО РАЙОНА Г.КАЗАНИ", СНИЛС=04670631656, ИНН=165604073570, E=it-cbo@yandex.ru, G=Ирина Юрьевна, SN=Потапова, CN=Потапова Ирина Юрьевна
Основание: Я являюсь автором этого документа
Местоположение: место подписания
Дата: 2023.11.08 13:52:56+03'00'
Foxit Reader Версия: 10.1.4

# Казан шәһәре Киров районының «252 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» МАМБУ балаларга татар теле өйрәтүче тәрбиячесенең 2023-2024 нче уку елы өчен эш программасы

Мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем стандартын күздә тотып,
укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде.

Әзерләде: Зиганшина Э.И.,
Зарипова Г.Х.

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз ........................................................................................................................ 3
1 НЧЕ БҮЛЕК. МАКСАТЧАНЛЫК ........................................................................................................ 4
1.1. Аңлатма язуы........................................................................................................................ 4
1.1.1.Программаның максаты һәм бурычлары ......................................................................................... 4
1.1.2. Программа принциплары .................................................................................................... 6
1.2. Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләре ....................................................................................... 6
«Татарча сөйләшәм» проекты буенча максат ориентирлары .................................................................... 7
«Туган телдә сөйләшәбез» проекты буенча максат ориентирлары ............................................................ 10
1.3. Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы..................................................................... 15
2 НЧЕ БҮЛЕК. ЭЧТӘЛЕКЛЕ .................................................................................................................. 17
2.1. «Татарча сөйләшәбез» проекты ............................................................................................. 17
2.2. «Туган телдә сөйләшәбез» проекты ...................................................................................... 37
2.3. Эш төрләре һәм формалары ................................................................................................. 56
2.4. Коррекцион һәм инклюзив эш ................................................................................................ 57
2.5. Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү ................................................................................ 58
2.6. Ата- аналар белән эш .......................................................................................................... 73
2.7. Педагогик коллектив белән эш ................................................................................................ 73
2.8. Мәктәп белән бәйләнеш ........................................................................................................ 74
III НЧЕ БҮЛЕК. ОЕШТЫРУ........................................................................................................... 75
3.1. Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар .......................................................................... 75
3.2. Материаль - техник яктан тәэмин ителеш ..................................................................................... 82
3.3. Балаларга туган (татар) телне өйрәтү буенча тәрбиятенең эш циклограммасы ................................................ 83

3.4. Белем бирү эшчәнлеге челтәре ........ 93
ӘДӘБИЯТ ........ 94
КУШЫМТА ........ 97

## Кереш сүз

Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә, үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү, төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора.

Эш программасы Федераль дәүләт белем стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

**Федераль җирлегендә:**

- 29.12.2012елдан № 273-ФЗ « Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;
- Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013елның  17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган);
- СанПиН 1.2.3685-21 « Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр” раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2021 ел 28 гыйнвар 2 нче номырлы боерыгы;
- “Мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү эшчәнлеген төп гомуми белем бирү программалары нигезендә оештыру һәм тормышка ашыру” (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел 30 август 1014 нче номерлы боергы);

**Төбәк җирлегендә:**

- Татарстан Республикасының 2013ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;
- Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында” Законы;

**Мәктәпкәчә белем учреждениесе җирлегендә:**

- МАМБУ Уставы;

- МАМБУнең төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе;

Эш программасы өч бүлектән (максатчанлык, эчтәлекле, оештыру) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота.

## 1 НЧЕ БҮЛЕК. МАКСАТЧАНЛЫК

### 1.1. Аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татар¬стан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәк¬ле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министр¬лар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010-2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, № 1174) мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды.

Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү програм¬масы (алга таба программа) «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре»нә (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карары) нигезләнеп төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларны татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен үз эченә ала. Програм¬ма мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклый торган норма-тив-хокукый актлар, документларга нигезләнә.

#### 1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары

Информацион – коммуникатив технологияләр, уен – ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып, тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру.

**Бурычлар:** 1. Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

3. Диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

4. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен, бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары, әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

### 1.1.2. Программа принциплары

Коммуникативлык принцибы балаларны татар телен аралашу ча¬расы буларак куллануга әзерли. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтә.

Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашырылу принцибы.

Дәвамчанлык принцибы балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тота.

Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлавында. Тел өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашуга, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел мате¬риалын бик теләп үзләштерәләр.

Индивидуальләштерү принцибы тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тота. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала.

Күрсәтмәлелек принцибы тел өйрәтүне, көндәлек тормыштагы һәртөрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, балаларның тирә-юньне танып белүендә төп чара булып торган уен аша үткәрә.

Интеграция принцибы - һәр сөйләм төренең үзенчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеояз-мада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү.Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр

## 1.2. Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләре

**«Татарча сөйләшәм» проекты буенча максат ориентирлары**
**Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) «Минем өем» проекты**
**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**

Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белә.

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белә.

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.

Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.

Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Татар телендә сөйләшү теләге бар.

Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.

Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.

Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны таба, күрсәтә белә.

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белә, сүзләрне дөрес, урынлы куллана.

Куелган сораугa раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес кулланана белә.

Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Сүз байлыгы аз.

Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.

Сорауларны аңлый, җавап бирә алмый.

Мин, син алмашлыкларын урынлы куллана белми.

**Зурлар төркеме (5-6 яшь) “Уйный – уйный үсәбез” проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**

Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белә.

Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта107 сүз кулланып татар телендә аралаша.

Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана.

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап, дөрес куллана.

“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Сүз байлыгы аз.

Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.

Сорауларны аңлый, мөстәкыйль рәвештә сорау куя белми.

Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана алмый.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты**

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.

Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләрен бар.

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Фигыльләрне урынлы куллана.

Җырлар, шигырьләр белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы аз.

Бирелгән лексиканы диалогик һәм монологик сөйләмдә куллана алмый.

“Бу кем?”, “Бу нәрсә?”, “Нәрсә кирәк?”, “Нинди?”, “Ничә?”, “Нишли?”, “Син нишлисең?” “Кая барасың?” сорауларын мөстәкыйль рәвештә куя белми. Фигыльләрне урынлы куллана белми.

**«Туган телдә сөйләшәбез» проекты буенча максат ориентирлары**
**Беренче кече яшьтәгеләр төркеме (2-3 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез»**

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**

**1. Баланың сүзлек запасы**

Бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрне дөрес билгели. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

Бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә, исем белән фигыльне, алмашлык белән фигыльне яраклаштыра ала. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

3. **Сөйләмнең аваз культурасы**

Бала биремнәрне теләп башкара, аваз иyaртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үз инициативасы белән яки тәрбияче кушуы буенча, рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

**1. Баланың сүзлек запасы**

Бала, предметларның исемен атаганда, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый .

Бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбиячене сорауларына өстәмә сораулар ярдәмендә генә җавап бирә.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

Бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиячене сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый . Бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячене сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

Бала 1—2 биремне генә үти ала.

Бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

Бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә .

Бала, җавап биргәндә, 2—3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә.

## Икенче  кече яшьтәгеләр төркеме (3-4 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез»

### Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**

**1.  Баланың сүзлек запасы**

Предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели

**2.	Сөйләмнең грамматик ягы**

Тәрбиячене сорауларына җавап биргәндә, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиячене сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3.	Сөйләмнең аваз культурасы**

Бала биремнәрне теләп башкара. Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди?

кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбияченең үтенече буенча рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклый, сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

**1. Баланың сүзлек запасы**

Предметларның исемен атаганда авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

Предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

Бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый.

Бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

Бала 1-2 биремне генә үти ала.

Бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара,аның артыннан кабатлый.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбияченең үтенече буенча рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклый, сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

## Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез»

### Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре

**Ирешелгән нәтиҗәләр:**

Бала дөрес, төгәл, мөстәкыйль җавап бирә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Тәрбияченең этәргеч сораулары буенча җавап бирә һәм зур булмаган төгәлсезлекләр җибәрә.

Баланың җаваплары зурлар биргән сорауга туры килми, сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлый, сорауны аңламый.

**Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме (5 - 7яшь) «Туган телдә сөйләшәбез»**

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр зурлар төркеме:**

**Танып белү**

Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне таный һәм әйтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында сөйли, аларны төркемли белә. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә. Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес әйтә. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында сөйли, адресын әйтә. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны белә, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара.

**Аралашу**

Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллана белә, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, иҗади хикәяләр төзегәндә интонацияләрдән дөрес файдалана. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана белә. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне дөрес әйтә белә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда теләп катнаша. Үстерешле аралашуда катнашу дәрәҗәсе камил.

**Матур әдәбият уку**

Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып, яттан сөйли.  Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сөйләмдә мөстәкыйль куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйләп бирә ала.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

**Танып белү**

Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тулысынча сөйләми, исенә төшергәч, өстәп сөйли белә, төркемли ала. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматны тулысынча биреп бетерә алмый. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзетурында аз сөйли, сораулар биргәч, үзлектән тулыландыра. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлатканда, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарганда кыенлыклар кичерә.

Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми, төркемли алмый. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматы юк. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында әйтә белми. Үз туганнары, үзе турында тәрбияче ярдәмендә сөйли. Адресын белми. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлата, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алмый.

**Аралашу**

Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр кулланганда хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белә. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә, бик үк мөстәкыйль түгел. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген тулы бирми, иҗади хикәяләр төзегәндә иҗади түгел. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда, ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйткәндә хаталар җибәрә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы камил дәрәҗәдә түгел.

Бала сөйләмдә гади җөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып, начар сөйли, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми, иҗади хикәяләренең эчтәлеге гади, интонацияләрдән файдаланмый. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтми. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда сирәк катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы юк дәрәҗәдә.

**Матур әдәбият уку**

Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аерганда ялгышлыклар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда активлык күрсәтми, ләкин катнаша. Язучыларны

таный, әсәрләрен әйтүдә кыенлыклар кичерә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сирәк куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя биргәндә, хаталар җибәрә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга тулы итеп сөйләми.

Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера алмый. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда катнашырга теләге юк. Язучыларны танымый, әсәрләрен әйтә алмый. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя бирә белми. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белми.

### 1.3. Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы

МББ ФДББС белән ярашлы рәвештә максат ориентирлары турыдан-туры, шул исәптән педагогик диагностика (мониторинг) рәвешендә дә, бәяләүгә алынмый һәм аларны балаларның реаль казанышлары белән формаль чагыштыру өчен нигез була алмый. Алар балаларның әзерлегенә һәм белем бирү эшчәнлегенә карата кабул ителгән таләпләргә туры килә торган объектив бәяләмәнең асылы булып тормый. Программаны үзләштерү арадаш аттестацияләр һәм тәрбияләнүчеләрнең йомгаклау аттестациясен уздыру белән кушылып китми. МББнең ФДББСннан күренгәнчә, максат ориентирлары идарә итү бурычларын хәл иткәндә турыдан-туры нигез була алмыйлар. Әлеге бурычларга түбәндәгеләр керә:

• педагогик кадрларны аттестацияләү;

• белем бирүнең сыйфатын бәяләү;

• балаларның соңгы, шулай ук арадаш үсеш дәрәҗәсен, шул исәптән мониторинг кысаларында бәяләү (шул исәптән күзәтүгә яисә балаларның нәтиҗәгә ирешүен тикшерүнең башка ысулларына нигезләнгән методлар кулланып тестлар уздыру формасында);

• максат ориентирларын биремне үтәүнең сыйфат күрсәткеченә кертү ярдәмендә муниципаль (дәүләт) биремнәренең башкарылуын бәяләү;

• оешма хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең стимуллаштыручы фондын билгеләү.

Әмма педагог үз эше барышында һәрбер баланың индивидуаль үсеш траекториясен булдырырга тиеш. Моның өчен педагогка үз эшен бәяләүнең балалар белән иң уңайлы рәвештә үзара бәйләнеш булдырырга ярдәм итүче инструментарие кирәк.

Тәкъдим ителгән Программаны үзләштерү нәтиҗәләрен бәяләү системасында мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын бәяләүне аңлауның үзгәрүе белән бәйле заманча тенденцияләр чагылыш таба. Беренче чиратта, игътибарны әкренләп объектив (тестлар уздыру) якын килүдән аутентик бәяләү ягына күчерү турында сүз бара. Тамырлары белән стандартлаштырылган тест традицияләренә китеп, объектив якын килү кысаларында тикшеренүләр махсус бурычларны хәл итү барышында балалардагы аерымлыкларны (еш кына җитешсезлекләрне) билгеләүгә юнәлтелгән иде. Әлеге тестлар килеп чыккан нәтиҗәләрне норма белән чагыштырырга мөмкинлек тудыра, шуның белән һәрбер баланың үз яшьтәшләре белән чагыштырганда үсеше турында мәгълүмат бирә. Шунлыктан мондый тестлар педагогик хәвефлелек төркеменә керергә тиешле балаларны ачыклауда киң кулланыла.

Әлеге ысулның төп җитешсезлеге шунда: ясалма биремнәр еш кына балаларның көндәлек тормышыннан шактый ерак, шуңа күрә алар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль мөмкинлекләрен тулысынча чагылдыра алмыйлар. Тест ысулы балаларның социаль даирәсе үзенчәлекләрен исәпкә алмый, һәм аның нәтиҗәләренә корылган фаразлар да шактый шартлы.

Аутентик бәяләүнең нигезендә түбәндәге принциплар ята. Беренчедән, асылда ул махсус биремнәрне үтәү нәтиҗәсенә түгел, баланың реаль тәртибен анализлауга карап корыла. Мәгълүмат турыдан-туры баланың тәртибен күзәтү ярдәмендә туплана. Күзәтү нәтиҗәләрен педагог гадәти тестларда куллана торган, мәктәпкәчә яшьтәге баланың реаль тормышына кагылышы аз булган уйлап чыгарылган ситуацияләрдә түгел,табигый мохиттә (уеннар вакытында, режим моментлары барышында, дәресләрдә) таба.

Икенчедән, әгәр тестларны махсус өйрәтелгән профессиональ белгечләр (психологлар, медицина хезмәткәрләре һ.б.) уздырса, аутентик бәяне исә бала белән озак вакыт булган, аның тәртибен яхшы белгән өлкәннәр куя ала. Бу очракта педагог тәҗрибәсе бәяләп бетергесез.

Өченчедән, аутентик бәя югары дәрәҗәдә структурлашкан. Ниһаять, әгәр тестлар ярдәмендә бәя кую очрагында ата-аналар алынган мәгълүматларның мәгънәсен һәрвакытта да аңлап бетермәсәләр һәм шуңа да еш кына балаларга тест

уздыруга тискәре мөнәсәбәт күрсәтсәләр, аутентик бәяләү вакытында җаваплар аларга аңлаешлы. Ата-аналар теге яисә бу сорауга җавап эзләгәндә педагогның партнерлары булып китәргә мөмкин.

# 2 НЧЕ БҮЛЕК. ЭЧТӘЛЕКЛЕ

## 2.1. «Татарча сөйләшәбез» проекты

### Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) «Минем өем» проекты

### Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары

1.Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклархисабына сүз байлыгын арттыру.
2.Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү.
3.Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү.
4.Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белү күнекмәләрен үстерү.
5.Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтару күнекмәләрен үстерү.

### Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

**Лексик минимум** – якынча 62 сүз.
“Минем өем” проекты темалары (“Гаилә”,“Ашамлыклар”,“Уенчыклар”,“Саннар”) буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (*әти, әни, бабай, әби, малай, кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю),* ашамлыклар *(алма, ипи, сөт, чәй)* һәм саннар *(бер, ике, өч, дүрт, биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *Алма бир. Мә, алма*.

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.

-*Бу кем? – Бу әти.*

-*Бу нәрсә? – Бу туп.*

Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.

-*Туп нинди? – Кечкенә.*

-*Машина нинди? – Матур.*

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).

-*Бу нәрсә? – Бу туп.*

-*Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боеремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).*

-*Мә, куян. – Бир куян.*

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү.

*Зур машина ал. Тәмле алма бир.*

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.

*Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз.* - *Мин Оля. Мин малай* - *Мин Коля.*

Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне *(әйе, юк)* дөрес кулланырга өйрәтү

*Син Коля? – Әйе.*

*Син кыз? – Юк, мин малай.*

Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.

*Син кем? – Мин Коля.*

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

## УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ «МИНЕМ ӨЕМ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

| **АКТИВ СҮЗЛӘР** | **СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ** | **АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>АНИМАЦИОН СЮЖЕТ** |
|---|---|---|
| **ГАИЛӘ – 18 СӘГАТЬ (1-18)** | | |
| әти<br>әни<br><br>малай<br>кыз<br><br>мин<br>исәнмесез<br>сау булыгыз<br><br><br><br>исәнме<br><br><br><br><br>эт<br>песи | -Бу кем?<br>-Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>-Кем юк?<br>-Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз).<br><br>-Исәнмесез.<br>-Син кем?<br>-Мин Коля (Оля).<br>-Мин малай.<br>-Сау булыгыз!<br><br>-Исәнме, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай).<br>-Сау бул, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>-Кем анда?<br>-Мин песи. Мин Мияу.<br>-Кил монда.<br>-Мин эт. Мин Акбай.<br>-Кил монда.<br><br>-Син Коля? | Аудиоязма №1-23<br><br>Дәфтәрдә эш №1-4<br><br>Сюжетлар:<br>1. “Әйдәгез, дуслашыйк”<br>2. “Качышлы уйныйбыз”<br>3. “Шалкан” |

| | | |
|---|---|---|
| әйе<br>юк<br>сау бул<br><br><br>әби<br>бабай<br><br><br><br><br><br><br><br><br>әйбәт | -Әйе, Коля.<br>-Син малай (кыз)?<br>-Әйе (юк).<br><br>-Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Әйе.<br>-Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Юк.<br><br>-Малай?<br>-Юк, кыз.<br>-Кыз?<br>-Әйе, кыз.<br><br>-Хәлләр ничек?<br>-Әйбәт. | |
| **АШАМЛЫКЛАР – 12 СӘГАТЬ (19-30)** | | |
| ипи<br><br>алма<br>сөт<br>чәй<br><br>мә<br>рәхмәт<br><br>тәмле<br>кил монда | -Мә, ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт, әби.<br><br>-Коля, мә ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт.<br><br><br><br><br>-Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля) | Аудиоязма №24-39<br><br>Дәфтәрдә эш №5-10<br>Сюжетлар:<br>1.“Тәмле” кибетендә”<br>2. “Азат кунак чакыра” |

<table>
<tr><td><br>утыр<br><br><br><br><br><br><br><br>аша<br>эч</td><td>-Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)?<br>-Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле. Рәхмәт.<br><br>-Мә, тәмле алма (ипи).<br><br>-Мә, ипи (алма) аша.<br>-Мә, сөт (чәй) эч.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">УЕНЧЫКЛАР – 18 СӘГАТЬ (31-48)</td></tr>
<tr><td>бир<br>туп<br><br>зур<br>кечкенә<br><br>матур<br>курчак<br><br>куян<br>аю</td><td>- Бу нәрсә?<br>- Туп (курчак, куян, аю).<br><br>-Курчак (туп, куян, аю) бир.<br>-Мә, курчак (туп, куян, аю).<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>-Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт).<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт).<br><br>-Аю (курчак, куян, туп)?</td><td>Аудиоязма №40-53<br><br>Дәфтәрдә эш №11-13<br><br>Сюжетлар:<br>1. “Паркка сәяхәт”<br>2. “Уенчыклар үпкәләгән”<br>3. “Күңелле уеннар”<br>4. “Акбай һәм Мияу мажаралары”</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| хәлләр ничек?<br>уйна<br>пычрак<br>чиста<br>ю | -Әйе.<br>-Курчак (аю, куян, туп)?<br>-Юк.<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна.<br><br>-Коля, кил монда. Уйна.<br>-Оля, кил монда. Уйна.<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) бир.<br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур.<br>- Аю (курчак, куян, туп) кечкенә.<br><br>- Мә, зур аю (курчак, куян, туп).<br>- Мә, кечкенә аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна).<br><br>-Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.<br><br>-Туп (курчак, куян, аю) нинди?<br>-Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>-Туп ю.<br>- Туп чиста?<br>- Юк, туп пычрак.<br>(Әйе, туп чиста).<br>Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю. | |

| САННАР - 6 СӘГАТЬ (49-54) | | |
|---|---|---|
| бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш | -Ничә?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br><br>-Ничә малай?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>-Ничә кыз?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br><br>-Өч?<br>-Юк.<br>-Ике?<br>-Әйе.<br><br>-Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54-60<br>Дәфтәрдә эш №14<br>Сюжет:<br>1.“Уйный-уйный саныйбыз” |
| **КАБАТЛАУ - 6 СӘГАТЬ (55-60)** | | |
| | | Аудиоязма №61-64<br>Дәфтәрдә эш №16-17<br>Сюжет:<br>1. “Күңелле ял итәбез” |

**Зурлар төркеме (5-6 яшь) «Уйный – уйный үсәбез» проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары**

1. Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белүләренә ирешү.
3.Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү.

4.Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.
5.Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**

**Лексик минимум** – якынча 45 сүз.
“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә,чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*
Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.
Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)*
Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.
- *Бу кызыл тәлинкә.*
“Минем өем” проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

## ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ

## «УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>АНИМАЦИОН СЮЖЕТ |
|---|---|---|
| **КАБАТЛАУ – 3 СӘГАТЬ (1-3)** | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | “Минем өем” проекты буенча | Аудиоязма №1<br><br>Дәфтәрдә эш №1<br><br>Сюжет:<br>1. “Шалкан” |
| **ЯШЕЛЧӘЛӘР – 21 СӘГАТЬ (4-24)** | | |
| кишер<br><br><br><br>баллы<br><br>ничә<br><br>суган<br>бәрәңге<br><br>кыяр<br><br>кәбестә<br>нинди<br><br>алты<br>җиде<br>сигез<br>тугыз | -Бу нәрсә?<br>-Кишер.<br>-Мә, кишер.<br><br>-Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>-Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Рәхмәт.<br><br>-Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак) | Аудиоязма №2-24<br><br>Дәфтәрдә эш №2-6<br><br>Сюжетлар:<br>1.“Баллы кишер”<br>2. “Уйный-уйный эшлибез”<br>3. “Юл маҗаралары”<br>4. “Кем эшләми, шул ашамый” |

| | | |
|---|---|---|
| ун<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>кызыл<br>сары | Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>-Мә кишер(алма), аша. Баллы?<br>-Әйе, баллы. Рәхмәт.<br><br>-Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>Сана.<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>-Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер).<br>-Рәхмәт.<br><br>-Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>-Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>-Сау бул, Коля.<br><br>-Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>-Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.<br><br>-Бу туп.<br>-Туп (алма) нинди?<br>-Туп (алма) сары (кызыл, яшел)<br><br>-Нинди туп (алма) юк? | |

| | | |
|---|---|---|
| яшел<br><br><br><br><br>нәрсә кирәк?<br><br><br><br><br><br><br><br><br>юа | -Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк.<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>-Кирәк.<br><br>-Коля, нәрсә кирәк?<br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>-Нинди кыяр?<br>-Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br><br><br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>-Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br>-Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа. | |
| **АШАМЛЫКЛАР – 6 СӘГАТЬ (25-30)** | | |
| аш<br>ботка | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй)<br><br>-Нәрсә кирәк?<br>-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).<br>-Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле. | Аудиоязма №25-29<br><br>Дәфтәрдә эш №7, 8<br><br>Сюжет:<br>1.“Аш бүлмәсе” |
| **САВЫТ-САБА - 6 СӘГАТЬ (31-36)** | | |

| | | |
|---|---|---|
| кашык<br>тәлинкә<br><br>чынаяк<br><br>зәңгәр | -Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-(1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30-37<br>Дәфтәрдә эш №9, 10<br>Сюжет:<br>1. “Өч аю”<br>2. “Чисталыкта - матурлык” |
| **КИЕМНӘР - 6 СӘГАТЬ (37-42)** | | |
| күлмәк<br><br>чалбар<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>ки<br><br><br><br>сал<br><br>йокла | яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br><br>чиста күлмәк (чалбар).<br>матур күлмәк (чалбар).<br><br>күлмәк (чалбар) юк.<br><br>-Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>-Нинди күлмәк (чалбар)?<br>-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>-Ничә күлмәк (чалбар)?<br>-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).<br><br>-Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>-Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>-Мә, чалбар (күлмәк).<br>-Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>-Курчак, йокла. | Аудиоязма №38-43<br><br>Дәфтәрдә эш №11, 12<br><br>Сюжет:<br>1.“Киемнәр кибетендә”<br>2.“Шаян уенчыклар” |

| | | |
|---|---|---|
| **ШӘХСИ ГИГИЕНА – 3 СӘГАТЬ (43-45)** | | |
| бит<br>кул<br>хәерле көн | -Хәерле көн.<br>-Мә су, бит (кул) ю.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br><br>-Бит (кул) чиста.<br>-Әйе, бит (кул) чиста. | Аудиоязма № 43, 44-48<br><br>Эш дәфтәре №13, 14<br><br>Сюжет:<br>1.“Ни өчен киемнәр югалган?” |
| **ӨЙ ҖИҺАЗЛАРЫ – 3 СӘГАТЬ (46-48)** | | |
| өстәл<br>урындык<br>карават | -Зур (кечкенә) урындык (өстәл, караватъ).<br><br>-Зур аю, мә зур караватъ (өстәл, урындык).<br>-Кечкенә аю, мә кечкенә караватъ (өстәл, урындык).<br><br>-Нәрсә кирәк?<br>-Караватъ (өстәл, урындык) кирәк.<br>-Нинди караватъ?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) караватъ.<br>-Мә, зур караватъ.<br>-Рәхмәт. | Аудиоязма № 49<br><br>Эш дәфтәре №15<br><br>Сюжет:<br>1.“Маша һәм өч аю” |
| **БӘЙРӘМ “ТУГАН КӨН” – 9 СӘГАТЬ (49-57)** | | |
| яратам | -Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.<br><br>-Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br><br>-Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам. | Аудиоязма №50-60<br><br>Эш дәфтәре №16-19<br><br>Сюжет:<br>1. “Туган көн”<br>2. ”Кем нәрсә ярата?” |

| | | |
|---|---|---|
| бар | -Нәрсә бар?<br>-Туп (курчак) бар.<br>-Нәрсә юк?<br>-Туп (курчак) юк.<br>“Бар”, “Юк” сүзләрен кулланып “Гаилә”, “Яшелчә” “Уенчыклар” темаларын кабатлау.<br>Диалогларны кабатлау.<br>“Кибетле” уеннары. | |
| **БӘЙРӘМ “САБАНТУЙ”- 3 СӘГАТЬ (58-60)** | | |
| | Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла.<br>“Гаилә”, “Яшелчә”, “Уенчыклар” темаларын кабатлау.<br>“Кибетле” уеннары. | Аудиоязма №61-63<br><br>Сюжет:<br>1.“Сабантуй бәйрәме” |

**Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары**

1. Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.
2. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
3. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.
4. Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**

**Лексик минимум** – якынча 60 сүз.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият ятабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер-сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер-йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла-җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

## МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

| АКТИВ СҮЗЛӘР | СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ | АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>АНИМАЦИОН СЮЖЕТ |
|---|---|---|
| син кем<br><br>хәерле көн | <br><br>-Хәерле көн, Оля (Коля).<br>-Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби). | Аудиоязма №1 - 2<br><br>Аудиоязма №3 - 5<br>Дәфтәрдә эш №1<br><br>Сюжет: “Мияу адашкан” |

| | | |
|---|---|---|
| тычкан | | Аудиоязма №6<br>Дәфтәрдә эш №2 |
| бу кем? | | Аудиоязма №7 - 8<br>Дәфтәрдә эш №3 |
| | | Сюжет:”Аю баласы дөнья белән таныша” |
| | | Аудиоязма №9 - 10<br>Дәфтәрдә эш №4 |
| бу нәрсә? | -Песи нишли?<br>-Песи йоклый. | Аудиоязма №11 |
| нишли?<br>йоклый<br>утыра | -Әни нишли?<br>-Әни утыра. | Сюжет: “Батыр Мияу һәм куркак Куянкай” |
| | | Аудиоязма №12<br>Дәфтәрдә эш №5 |
| ашый<br>эчә | -Коля нишли?<br>-Коля ашый (эчә). | Аудиоязма №13 - 14 |
| нишлисең?<br>ашыйм<br>эчәм | -Мияу, нишлисең?<br>-Ашыйм.<br>-Акбай, нишлисең?<br>-Эчәм. | Мультфильм:<br>“Тату гаилә” |
| | | Аудиоязма №15 |

| | | |
|---|---|---|
| уйный<br>уйныйм<br><br>утырам<br><br><br><br><br><br><br>барам<br>кая барасың?<br>син нишлисең?<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>сикер-сикерәм<br><br><br><br><br>сикерә<br>йөгерә<br>төлке | -Оля (Коля), нишлисең?<br>-Уйныйм.<br><br><br><br><br><br><br><br><br>-Кая барасың?<br>-Кафега барам.<br>-Син нишлисең?<br>-Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклый)<br><br><br><br><br><br><br><br>Туп, туп<br>Матур туп.<br>Сикер-сикер,<br>Матур туп.<br><br>Куян сикерә (йөгерә).<br>Туп сикерә.<br>Песи сикерә (йөгерә).<br>Төлке сикерә (йөгерә). | <br>Аудиоязма №16 - 18<br><br>Мультфильм: “Юмарт аю”<br><br>Аудиоязма №19<br><br>Аудиоязма №20<br>Дәфәрдә эш №6<br><br><br>Мультфильм: “Кафега барабыз”<br><br>Дәфтәрдә эш №7<br><br><br><br><br>Аудиоязма №21-23<br><br><br><br>Мультфильм:<br>“Урманда күңелле уеннар”<br><br>Аудиоязма №24<br>Дәфтәрдә эш №8<br><br>Аудиоязма №25-28 |

| | | |
|---|---|---|
| йөгер-йөгерәм | -Йөгер! Син нишлисең?<br>-Мин йөгерәм. | Мультфильм:<br>“Көчлеләр, кыюлар, җитезләр” |
| чәк-чәк<br>өчпочмак | -Мин чәк-чәк ашыйм.<br>-Мин өчпочмак ашыйм. | Аудиоязма №29-30<br>Дәфтәрдә эш №9 |
| яшь | -Сиңа ничә яшь?<br>-6 яшь. | Сюжет:<br>“Җәнлекләр спорт бәйрәмендә”<br><br>Аудиоязма №31-32 |
| бүре<br>керпе | -Мин бүре. Мин зур, матур, чиста. | Аудиоязма №33-34<br>Дәфтәрдә эш №10 |
| тавык<br>әтәч | Әтәч зур, матур<br>Тавык кечкенә, матур | Сюжет:<br>“Циркта”<br><br>Аудиоязма №35 - 36<br>Дәфтәрдә эш №11 |
| үрдәк | -Син кем?<br>-Мин үрдәк. | Аудиоязма №37 - 38<br>Дәфтәрдә эш №12 |
| чана<br>шуа | Куян чана шуа. | Сюжет:<br>“Шаян кошлар”<br><br>Аудиоязма №39 - 40 |

| | | |
|---|---|---|
| шуам<br><br><br><br><br><br>бие<br>бии<br><br>биим<br><br><br><br><br><br><br>ак<br>кара<br><br><br><br>жырла-жырлыйм<br><br><br><br><br><br><br><br><br>зур рәхмәт | Мин чана шуам.<br><br><br><br><br><br>-Аю, әйдә, бие!<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>-Оля кызыл шар ярата?<br>-Юк.<br>-Оля яшел шар ярата?<br>-Әйе, мин яшел шар яратам.<br><br>-Син нишлисең?<br>-Мин жырлыйм.<br><br><br><br><br><br>жырлыйбыз<br>зур рәхмәт | <br><br>Аудиоязма №41<br>Дәфтәрдә эш №13<br><br>Сюжет:<br>“Урманда зур концерт”<br><br>Аудиоязма №42 - 44<br>Дәфтәрдә эш №14<br><br><br><br><br>Аудиоязма №45 - 46<br><br>Сюжет: “Акбай туган көнгә барырга жыена”<br><br>Аудиоязма №47<br>Дәфтәрдә эш №15<br><br>Аудиоязма №45, 48 – 49<br><br>Сюжет:<br>“Мияуның туган көне”<br><br>Аудиоязма №50<br>Дәфтәрдә эш №16<br><br>Аудиоязма №51 - 53 |

| | | |
|---|---|---|
| | | Дәфтәрдә эш №17<br><br>Сюжет:<br>“Урман китапханәсендә” |
| китап укый | Кыз китап укый. | Аудиоязма №54 - 60<br>Дәфтәрдә эш №18 |
| рәсем ясыйм | рәсем ясыйм-алма ясыйм<br>мәктәп | Сюжет “Уйный-уйный укыйбыз”<br><br>Аудиоязма №61-63<br>Дәфтәрдә эш №19 |
| укыйм | -Кем укый.<br>-Мин укыйм. | Сюжет: “Урман мәктәбендә”<br><br>Аудиоязма №64<br>Сюжет: “Теремкәй”<br><br>Аудиоязма №65-66 |
| дәфтәр | бик тәмле | Сюжет: “Кем нәрсә ярата?”<br><br>Аудиоязма №67 - 71<br>Дәфтәрдә эш №20 |
| | Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Теремкәйдә төлке яши.<br>Теремкәйдә аю яши.<br>Алар бик дус.<br><br><br>-Кәҗә кая?<br>-Әнә, кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.<br><br>-Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>-Мин сөт яратам. Сөт тәмле.<br><br>-Мә, кәҗә, ботка аша.<br>-Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле. | |

## 2.2. «Туган телдә сөйләшәбез» проекты

## «Туган телдә сөйләшәбез». Комплекслы тематик план (2-3 яшь)

| № | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Танышу** | Танышу | 6 |
| 2. | **Безнең балалар бакчасы** | Аю белән куян кунакка килгән<br>Куянга өй төзибез<br>Курчагым<br>“Үчтеки, үчтеки” такмагын уку<br>Курчакның туган көне<br>Карусельгә сәяхәт<br>Минем матур тубым | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Әминә Бикчәнтәеваның “Туп-туп, тубыбыз” шигырен уку<br>Уенчыклар кибетендә | 1<br>1<br>1<br><br>1 |
| 3. | **Көз** | Көз җитте<br>Көзге яфраклар<br>”Безнең Алсу “ сериясеннән рәсем карау<br>Яшелчәләр<br>Куян кунакка килгән<br>“Шалкан” әкияте<br>Җиләк-җимешләр<br>Әбидә кунакта<br>Яшелчә бакчасында | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4. | **Мин - дөньяның бер кешесе** | Минем исемем бар<br>Бу — мин<br>Мин –дөньяның бер кешесе | 1<br>1<br>1 |
| 5. | **Гаилә** | Минем гаиләм<br>Безнең гаилә<br>Әйдәгез дуслашыйк<br>Бу өйдә кем яши?<br>Без чәбәкәй итәбез<br>Уйнарга яратабыз<br>“Гаилә” рәсемен карау<br>Шәйхи Маннурның “Яратам” шигырен уку<br>Әйдәгез уйныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 6. | **Кыш** | Ап-ак кар ява<br>Алсу урамга җыена<br>Кар бабай ясау<br>Кыш рәсемен карау<br>Кар ява | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | А.Алиш “Куян кызы” | 1 |
| 7. | **Яңа ел бәйрәме** | Яшел чыршы<br>Әминә Бикчәнтәеваның «Беренче адым» шигырен уку<br>Чыршы бизибез<br>Куян чыршы янында<br>Купшы чыршы<br>Без музыка залында | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 8. | **Минем әйләнә - тирәм** | Яраткан уен бүлмәбез<br>Алсу бүлмәсе<br>Безнең урам<br>Безнең апа<br>Алсу авырган<br>Алсуда кунакта<br>Безнең йортта нәрсәләр яши?<br>Йорт кошлары<br>Хайваннарны чакыру<br>Маэмаем<br>М.Җәлилнең “Әтәч” шигырен уку<br>Гав исемле мәче баласы<br>Габдулла Тукай “Гали белән Кәҗә”<br>“Чуар тавык” әкияте<br>Әкияттә кунакта | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 9. | **Әтиләр-бабайлар** | Зур гаилә<br>Безнең әтиләр һәм абыйлар<br>Бабайга кунакка барабыз<br>Машина<br>Самолет<br>Булатның машинасына гараж ясау | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | **Әниләр-әбиләр** | Кибеткә бару<br>Әбидә кунакта<br>Безнең әниләр<br>Алсуны табибка алып барабыз<br>Табибка барабыз<br>Курчакны йоклату | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
